РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**21.09.2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№1**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты, 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм 2020 елның 21 сентябрендәге 2 номерлы хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР итә:**

1. "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга, шуның нигезендә Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы рәисе итеп 5 нче номерлы Алан-Бәксәр бермандатлы сайлау округы депутаты Гарифуллина Зөһрә Рөстәм кызын сайларга.

2. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына керешү көне итеп Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көнне санарга.

3. «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставының 43 статьясының 5-нче өлеше нигезендә Гарифуллина Зөһрә Рөстәм кызын Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куярга.

4. Әлеге Карарны Алан-Бәксәр авыл җирлеге составына кергән барлык торак пунктларда мәгълүмати стендларда урнаштырырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урныштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Рәислек итүче Г.Н.Анастасов